РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«1» февраля 2021 ел г. Альметьевск № 96

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының«Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 6 августындагы 1089 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында

Хокукый мониторинг тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының«Торак урыннарына мохтаҗ гражданнарның аерым категорияләрен исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2020 елның 6 августындагы 1089 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 декабрендәге 1982 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

8 пунктчада) 2 нче бүлектәге 2.6 нчы таблицадагы графлар түбәндәге сүзләр белән өстәргә:

««Инвалидлар федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан, ә мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә «Инвалидларның федераль реестры» Федераль дәүләт мәгълүмат системасында тиешле белешмәләр булмаган очракта.».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең төзелеш буенча урынбасары Д.В. Косаревка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 305-2000